ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.03.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1021**

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 15 апрелендәге «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 190 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәүгә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкару комитетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2024 елның 16 октябрендәге 3924 номерлы, «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 3924 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 19 мартындагы 715 номерлы,«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 16 октябрендәге 3924 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 15 маендагы 1324 номерлы карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2026 елның 26 мартындагы
1021номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын һәм тәртибен (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү) билгели.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алучылар (алга таба - мөрәҗәгать итүче):

а) торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән (я язылышмаган булса, үз исеменнән) гариза белән мөрәҗәгать итүче, үзе бу гаиләнең әгъзасы булып торган Татарстан Республикасы кешесе;

б) Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, үзе әгъзасы булган яшь гаилә исеменнән мөрәҗәгать итүче Россия Федерациясе гражданы;

в) Татарстан Республикасында авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән (яисә, әгәр язылышмаган булса, үз исеменнән) мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданы.

г) Россия Федерациясе гражданы, социаль ипотека системасында исәпкә кую максатында мөрәҗәгать итүче махсус хәрби операциядә катнашучы, ә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә ул һәлак булган очракта – аның гаилә әгъзалары (аның белән бергә даими яшәүче хатыны (ире) һәм аларның балалары), әгәр ул элек әлеге категория буенча торак шартларын яхшырту хокукын гамәлгә ашырмаган булса, түбәндәге шартларга туры килә торган:

- Татарстан Республикасы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган йә махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Татарстан Республикасындагы хәрби комиссариатларда йә Татарстан Республикасында урнашкан хәрби частьләрдә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән;

- махсус хәрби операциядә катнашуны тәмамлаган яки махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган;

- махсус хәрби операциядә катнашу тәмамланган көнгә йә махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган көнгә Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең мәнфәгатьләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә вәкаләт бирелгән затлар һәм физик затларның законлы вәкилләре (алга таба – мөрәҗәгать итүче вәкиле)тәкъдим итәргә мөмкин.

3. Муниципаль хезмәт мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүченең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» (алга таба – Бердәм портал) федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла торган категорияләре (билгеләре)нигезендә күрсәтелергә тиеш.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

Муниципаль хезмәт күрсәтү атамасы

4. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую һәм яңадан теркәү.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның аталышы

5. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе

6. Мөрәҗәгать итүче «Исәпкә кую»ны сорап мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре булып:

1) социаль ипотека буенча торак шартларын яхшырту өчен мөрәҗәгать итүченең гаиләсен исәпкә кую турында карар (5 нче кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (6 нчы кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын төзү каралмаган.

7. Мөрәҗәгать итүче «Яңадан теркәү»не сорап мөрәҗәгать иткәндә муниципаль хезмәт нәтиҗәләре булып:

1) гаилә исәп-хисап эшен яңадан теркәү турында карар (5 нче кушымта);

2) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар (6 нчы кушымта).

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язмасын төзү каралмаган.

8. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә Башкарма комитетның вазыйфаи затының (яки Башкарма комитетның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә Бердәм портал, Республика порталының (алга таба – Республика порталы) шәхси кабинетына җибәрелә.

9. Мөрәҗәгать итүче сайлавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесендә (алга таба – КФҮ) Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән, кәгазьдә бастырылган, КФҮ мөһере һәм КФҮ хезмәткәре имзасы белән таныкланган электрон документ нөсхәсе рәвешендә алынырга мөмкин.

10. Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә яисә электрон документның нөсхәсен кәгазь саклагычта муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы эчендә алырга хокуклы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы

11. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 22 эш көненнән артмаска тиеш

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң килә торган көннән исәпләнә башлый.

12. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гаризаны теркәгән көннән соң килә торган көннән исәпләнә башлый.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны электрон документ формасында җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

13. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документны Башкарма комитетта һәм КФҮдә бирү мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаны һәм документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

14. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаларны һәм документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карарны Башкарма комитет түбәндәге нигезләр булганда кабул итә:

1) Регламентның 3 нче кушымтасында күрсәтелгән, мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документларны тапшырмау;

2) ведомствоара мәгълүмати бәйләнеш кысаларында соратып алынган законлы вәкилләр турында белешмәләр расланмау, гариза (рәсми мөрәҗәгать) бирүнең моңа вәкаләтле булмаган зат тарафыннан тапшырылуы;

3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

4) дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны, эчтәлеген төгәл аңларга мөмкинлек бирми торган килешенмәгән төзәтүләрне, җитди бозуларны үз эченә алган документлар, гамәлдән чыккан документлар тапшыру;

5) Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булып тормаган затның муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итүе;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри тутырылырга тиешле юлларны дөрес тутырмау, гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы белешмәләр булу;

7) электрон рәвештәге гаризага (рәсми мөрәҗәгатькә) һәм башка документларга электрон имза гамәлдәге законнарны бозып куелган;

8) электрон документлар тапшыру форматларына куелган таләпләргә туры килми һәм (яисә) укылмыйлар.

15. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

16. Мөрәҗәгать итүченең категориясен (билгеләрен) исәпкә алып муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

## Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

17. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен түләү алу Россия Федерациясе кануннары белән каралмаган.

## Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен рәсми мөрәҗәгать иткәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

18. Муниципаль хезмәт алу өчен гариза биргәндә көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

19. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

## Мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы

20. КФҮкә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, гариза тапшырылган көнне КФҮ АМСсыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаның җибәрелүен раслый торган теркәү номеры һәм гариза тапшыру датасы күрсәтелгән раслама бирелә.

21. Гаризаны Бердәм , Республика порталы аша җибәргәндә мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне Бердәм , Республика порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, гаризаның теркәлү номерын һәм гариза бирү датасын күрсәтеп, гариза җибәрелгәнлеген раслый торган хәбәрнамә ала.

22. Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаны ике нөсхәдә тапшырган көнне, Башкарма комитетның вәкаләтле вазифаи заты тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелгән документлар күрсәтелгән бер нөсхәсе кире кайтарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

23. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү урыннары документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

24. Инвалидларны социаль яклау турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатыннан түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге (биналарга/биналардан уңайлы керү/чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү);

2) муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында урнаштырылган визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып;

3) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе тотрыклы бозылулары булган инвалидларны озата бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

4) социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, шул исәптән кресло-колясканы файдаланып мондый объектларга керү һәм чыгу, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;

5) инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат саклагычларын тиешенчә урнаштыру;

6) инвалидлар өчен кирәкле ишетеп һәм күреп була торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне, башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-ноктaлы Брайль шрифтын кулланып башкарылган билгеләр белән кабатлап бирү;

7) сурдотәрҗемәчегә һәм тифлосурдотәрҗемәчегә керергә рөхсәт итү;

8) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау Министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге «Озатып йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 386н номерлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча бирелә торган документ булган очракта, юл күрсәтүче этне кертергә рөхсәт итү.

25. Муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан һәм хезмәт күрсәткәндә кулланыла торган чаралардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр, Регламентның 27 пунктының 1 - 4 пунктчаларында күрсәтелгәнчә, 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация, реконструкция үткәрелгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

26. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга куелган таләпләр турында мәгълүмат Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр порталы

составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, КФҮ, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре

27. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләр:

документларны кабул итү алып барыла һәм тапшыра торган бинаның җәмәгать транспорты йөргән урыннарга якын урнашуы;

кирәкле белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга башка затлар белән берләттән тигез дәрәҗәдә хезмәт күрсәтүне алуда комачаулый торган каршылыкларны узуда ярдәм итү.

28. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срогын үтәү;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

4) мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән аралашу саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) Хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең КФҮ хезмәткәрләре белән аралашуы гариза белән барлык кирәкле документларны биргәндә бер тапкыр башкарыла;

4.2) Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күпфункцияле үзәктә электрон документның кәгазь нөсхәсе рәвешендә алу кирәк булган очракта – бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазифаи затлар белән бер тапкыр аралашу озынлыгы 15 минуттан артмый.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып бәяләргә хокуклы.

29. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы һәм статусы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталдагы шәхси кабинетта яисә Республика порталында, күп функцияле үзәктә алынырга мөмкин.

30. Муниципаль хезмәт күрсәтү мөрәҗәгать итүче сайлаган теләсә кайсы КФҮтә, аның яшәү урынына яисә фактта яшәү (булу) урынына бәйсез рәвештә, экстерриториаль принцип буенча башкарыла.

31. Муниципаль хезмәт күрсәтүенең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфат күрсәткечләре турында мәгълүмат Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, КФҮ, шулай ук Бердәм һәм Республика порталларында урнаштырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр

32. Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүче:

а) Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм срогы турында мәгълүмат алырга;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон образлары элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешенең 7.2 пункты нигезендә

расланган документларны һәм мәгълүматны Республика порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларны үтәүнең барышы һәм статусы турында белешмәләр алырга;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын Бердәм, Республика порталы аша бәяләргә;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

е) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазифаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә башкарылган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) Бердәм портал, Республика порталы, судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша Башкарма комитетның, шулай ук аның вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерергә.

33. Гаризаны формалаштыру Бердәм, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән, өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада гариза бирү кирәклегеннән башка гамәлгә ашырыла.

34. КФҮтә  мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итү буенча язу (алга таба - язылу) Республика порталы, КФҮ контакт-үзәге телефоны аша алып барыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге көн башланырга бер тәүлек кала тәмамлана.

Бердәм, Республика порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә соратып алынган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (теләк буенча);

кабул итү буенча теләгән көнен һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу вакытында хәбәр ителгән белешмәләр шәхси кабул итү вакытында мөрәҗәгать итүче тапшырган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны бастырып чыгару мөмкинлеге тәэмин ителә. Мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасы, вакыты һәм урыны күрсәтелгән алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, мөрәҗәгать итүче билгеләнгән кабул итү вакытыннан соң 15 минут үткәч килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарылуы турында аңа мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче алдан язылу вакытыннан теләсә кайсы вакытта баш тартырга хокуклы.

Мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы аралыгын исәпләп чыгару өчен кирәк булган белешмәләр бирүдән тыш, башка гамәлләр кылуны таләп итү тыела.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

35. Регламентка 3 нче кушымта таблицасында муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге китерелгән, алар түбәндәгечә бүленә:

а) Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле документлар;

б) Хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга хокуклы документлар.

36. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар формалары турында мәгълүмат әлеге Регламентның 3, 8, 9 нчы кушымталарында китерелгән.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары

Административ процедуралар исемлеге

37. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
1) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза һәм документлар кабул итү;
2) ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш;
3) комиссия утырышын үткәрү;
4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
5) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен
гариза һәм документлар кабул итү

38. Муниципаль хезмәт күрсәтүгә рәсми мөрәҗәгатьне теркәү әлеге Регламентның 20-22 пунктларында күрсәтелгән срок эчендә башкарыла.

39. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына китерелгән документлар мөрәҗәгать итүченең категориясе (билгеләре) нигезендә Башкарма комитетка, Бердәм, Региональ портал аша, КФҮгә тапшырылырга мөмкин.

40. Бердәм, региональ портал аша гариза биргән очракта, мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр бердәм идентификация һәм аутентификация системасындагы хисап язмасы күрсәтелгән хисап язмасының тиешле күрсәткечләре составыннан расланганда төзелә һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан файдаланып, рәсми мөрәҗәгать җибәрү юлы белән тикшерелергә мөмкин.

Башкарма комитетка, КФҮкә гариза биргән очракта, мөрәҗәгать итүче хезмәт күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать иткәндә шәхесне таныклаучы документның төп нөсхәсен күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче вәкиле рәсми мөрәҗәгать биргән очракта, вәкил үзенең вәкаләтләренраслый торган документның төп нөсхәсен (Башкарма комитетта, КФҮтә рәсми мөрәҗәгать тапшырганда) йә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган, шул исәптән нотариуслар белән (КФҮ биргәндә Республика порталы ярдәмендә) үзенең вәкаләтләрен раслый торган документның электрон образын күрсәтә.

41. Мөрәҗәгать итүчеләр гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә гаризага гади электрон имза белән имзлыйлар.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәп язмасын стандарт дәрәҗәдән түбән булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк

Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән юридик затлар һәм юридик затларның вәкилләре, гариза һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

## Ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеш

42. Муниципаль хезмәт алу алу өчен «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» муниципаль торак фондының муниципаль торак фонды бүлеге белгече тарафыннан «Ведомствоара электрон үзара бәйләнешнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрергә кирәк:

1) «Аерым затның үзендә булган күчемсез мөлкәт объектларына хокуклары турында Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (соңгы 3 ел өчен)» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать. муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

2) «Күчемсез мөлкәт объекты һәм (яисә) аларның хокук ияләре турында бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрыннан өземтә» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать. муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте»нә җибәрелә. «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 2 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

3) «Мөрәҗәгать итүченең гаиләсенең 14 яшькә җитмәгән барлык әгъзалары өчен туу турында таныклык» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» Хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

4) «Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен язылышу факты булганда язылышу турында таныклык» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

5) «Аталыкны билгеләү турында таныклык, әгәр аталыкны билгеләү факты булса». дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

6) «Фамилиясен, исемен, атасының исемен алыштыру факты булганда фамилиясен, исемен, атасының исемен алыштыру турында таныклык» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

7) « Аерылышу турында турында таныклык» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

8) «Гаилә составын раслау өчен үлем факты булган очракта үлем турында таныклык» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

9) «Махсус салым режимнарын кулланучы физик затларның, индивидуаль эшкуарларның керемнәре турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

10) «Салым органнарында исәпкә кую турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәтенә» муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

11) «Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр түләү буенча бурычларның булмавы турында гаиләнең барлык әгъзаларына салым органы белешмәләре» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Федераль салым хезмәте»нә муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Федераль салым хезмәте» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

12) «Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары нигезендә алынган түләүләр рәвешендә физик затлар файдасына иминият кертемнәрен түләүчеләр тарафыннан башкарылган түләүләр турында, пенсияләр, пособиеләр һәм социаль ярдәмнең башка чаралары турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Россия социаль фонды»на муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Россия социаль фонды» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

13) «Индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлү турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Россия социаль фонды»на муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Россия социаль фонды» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

14) «Иминият стажы турында белешмәләр»дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Россия социаль фонды»на муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Россия социаль фонды» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

15) «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр»дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Россия социаль фонды»на муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә җибәрелә. «Россия социаль фонды» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгәннән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

16) «Яшәү (булу) урыны турында белешмәләр»дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра;

17) «Россия Федерациясе гражданины паспорты турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать.. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

18) «Россия Федерациясе гражданины паспортының сериясе һәм номеры буенча гамәлдә булуын тикшерү» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

« Килү урыны, яки яшәү урыны буенча теркәлгән, шулай ук бер адрес буенча бергәләп миграция исәбендә торучы затлар турында белешмә» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза теркәлгән көннән алып 1 эш көне эчендә «Эчке эшләр министрлыгы»на җибәрелә. «Эчке эшләр министрлыгы» соратып алына торган белешмәләрне ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәрелгән вакыттан алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшыра.

43. Муниципаль хезмәт күрсәтүне алу өчен башка сервислар аша түбәндәге ведомствоара мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать җибәрү кирәк:

1) «Торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турындагы белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

2) « Гражданнарның аерым категорияләре торак белән тәэмин итү буенча федераль һәм республика программаларында катнашуы турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Башкарма комитетның структур бүлекчәсеннән 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

3) «Пособиеләр билгеләү турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча соратып алына;

4) «Ышанычнамәне бирү факты һәм эчтәлеге турында белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать мөрәҗәгать итүче вәкиле хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта «Нотариатның бердәм мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

5) «Билгеләнү турында опека органы актыннан белешмәләр» дигән рәсми мөрәҗәгать. Күрсәтелгән мәгълүмати рәсми мөрәҗәгать «Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасы» сервисы ярдәмендә 1 эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

### Комиссия утырышын үткәрү

44. Комиссия утырышы «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлеге белгече (алга таба - комиссия

үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат) Регламентның 42-43 пунктларында билгеләнгән административ процедура тәмамланганнан соң 13 эш көне эчендә уздырыла.

45. Комиссия утырышын уздыру нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

- мөрәҗәгать итүченең гаиләсен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую турында карар;
- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турындагы карар;
- яңадан теркәү турында карар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

46. . Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында каралган нигезләр булган очракта, «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлеге белгече (алга таба - муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат) әлеге Регламентның 42-43 пунктларында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар әзерли

47. Әгәр дә әлеге Регламентның 4 нче кушымтасында каралганча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаса, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат, әлеге Регламентның 42-43 пунктларында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә, мөрәҗәгать итүченең гаиләсен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кую турында яки яңадан теркәү турында карар  әзерли.

Мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тапшыру

48. Хезмәт нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә Регламентның 46-47 пунктларында билгеләнгән процедураларның үтәлеше тәмамланган көнне бирелә.

Мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысулы буларак Бердәм, Республика порталын сайлаган очракта, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә яшәү урынына яисә килү урынына яисә булу урынына бәйсез рәвештә күрсәтелә

**IV.Дәүләт хезмәт күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне  карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары**

49. Техник мөмкинлек булганда, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламент белән билгеләнгән хезмәт күрсәтүгә гариза статусын үзгәртү турында (хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү турында; гаризаны һәм документлар комплектын карау турында; хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу турында), шулай ук мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт күрсәтүнең бирелгән этабында башкарырга тиешле алдагы адымнар һәм гамәлләр турында, санап үтелгән ысулларның берсе белән хәбәр ителә:

– смс-мәгълүмат бирү юлы белән;
– Бердәм портал ярдәмендә;
– Республика порталы ярдәмендә;
– башка сервислар һәм ысуллар ярдәмендә (булган очракта).

Регламентка
1 нче кушымта

**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР ҺӘМ КЫСКАРТЫЛМАЛАР ИСЕМЛЕГЕ**

1) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (https://uslugi.tatarstan.ru/) – Республика порталы;
2) Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (https://www.gosuslugi.ru/) – Бердәм портал;
3) Федераль дәүләт мәгълүмат системасы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең федераль реестры» (http://frgu3.gosuslugi.ru) Реестр);
4) Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (https://www.zelenodolsk.tatarstan.ru);
5) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты – Башкарма комитет;
6) Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – КФҮ.
7) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы (http://msu.tatarstan.ru)

Регламентка
2 нчы кушымта

**Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары**

| № | Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билге атамасы | Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым билге идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Исәпкә кую | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән үзенең әгъзасы булган (яисә бракта тормаса, үз исеменнән) гариза белән мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы кешесе | 1А |
| 2. | | Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, үзе әгъза булып торган яшь гаилә исеменнән гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины | 2А |
| 3. | | Татарстан Республикасында авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән гариза бирүче Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе ражданины (яисә, әгәр бракта тормаса, үз исеменнән) | 3А |
| 4. | | Россия Федерациясе гражданины, махсус хәрби | 4А |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | операциядә катнашучы, әгәр ул махсус хәрби операциядә катнашу вакытында һәлак булса, аның гаилә әгъзалары, әгәр аларга элек торак шартларын яхшырту хокукы бирелмәгән булса | |
| 5. | | Мөрәҗәгать итүче вәкиле | 5А |
| 1. | Кабат теркәлү | Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән үзенең әгъзасы булган (яисә бракта тормаса, үз исеменнән) гариза белән мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы кешесе | 1Б |
| 2. | | Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, үзе әгъза булып торган яшь гаилә исеменнән гариза бирүче Россия Федерациясе гражданины | 2Б |
| 3. | | Татарстан Республикасында авыл торак пунктларында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә исеменнән гариза бирүче Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе ражданины (яисә, әгәр бракта тормаса, үз исеменнән) | 3Б |
| 4. | | Россия Федерациясе гражданины, махсус хәрби операциядә катнашучы, әгәр ул махсус хәрби операциядә катнашу вакытында һәлак булса, аның гаилә әгъзалары, әгәр аларга элек торак шартларын яхшырту хокукы бирелмәгән булса | 4Б |
| 5. | | Мөрәҗәгать итүче вәкиле | 5Б |

Регламентка
3 нчы кушымта

**Хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге**

| № | Идентификатор | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның төрләрен ачыклау, бу төркемдәге документлар саны | Тапшыру ысулы |
|---|---|---|---|
| *Мөрәҗәгать итүче Хезмәт күрсәтү өчен мөстәкыйль рәвештә тапшырырга тиешле документлар* | | | |
| 1. | 1А-5А, 1Б-5Б | Гариза, анкета (8 нче, 9 нчы кушымталар) | Башкарма комитет |
| 2. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ | Башкарма комитет, КФҮ |
| 3. | 5А, 5Б | Мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ | Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүченең, аның гаилә әгъзаларының хокуклары Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар (торак урынга һәм җиргә милек турындагы таныклык, аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк бирү шартнамәсе һ.б.) яисә аларның нотариаль таныкланган күчермәләре; | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 5. | 1А-5А, 1Б-5Б | Ордер (наем, поднаем, аренда, субарендлар шартнамәсе) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 6. | 1А-5А, 1Б-5Б | Торак бинага хокук Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән очракта, торак урынның техник планы яисә техник паспорты | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | (фатирлар, йортлар); | комитет, КФҮ |
| 7. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының хезмәт кенәгәсе (барлык битләренең эш бирүче тарафыннан таныкланган күчермәсе) яисә 2020 елның 1 гыйнварына кадәрге чорлардагы хезмәт стажы турындагы документлар, хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырылмаган очраклардан тыш | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 8. | 1А-5А, 1Б-5Б | Студент билеты яки уку урынын раслый торган документ (укучылар өчен), балалар бакчасыннан белешмә (мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 9. | 1А-5А, 1Б-5Б | Хәрби хезмәт узу турында белешмә | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 10. | 1А-5А, 1Б-5Б | Һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада укучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендия күләме яисә күрсәтелгән категориядәге гражданнарга медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булу чорында компенсация түләү күләме турында(тиешле түләүләрне алучы (алучы) затлар өчен) тиешле белем бирү оешмасы тарафыннан бирелгән белешмә | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 11. | 1А-5А, 1Б-5Б | Аталыкны билгеләү яки аталыкны тану фактын билгеләү турында законлы рәвештә гамәлгә кергән суд карары булган очракта (суд карарын кабул иткән суд тарафыннан расланган күчермә) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 12. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүчегә һәм/яки аның гаилә әгъзаларына карата туганлык мөнәсәбәтләрен билгеләү яки туктату, ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү, вафат, хәбәрсез югалган дип тану турында суд карары булган очракта, законлы рәвештә гамәлгә кергән әлеге суд карары (суд карарын кабул иткән суд тарафыннан расланган күчермә) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 13. | 1А-5А, 1Б-5Б | Гражданинның социаль ярдәм алу хокукын раслый торган таныклыклар һәм документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 14. | 1А-5А, 1Б-5Б | Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбенә кабул ителә торган затлар өчен шушы хокукны исәпкә алып өстәмә мәйданга хокук турындагы документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 15. | 1А-5А, 1Б-5Б | Чит ил дәүләтенең вәкаләтле органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве турында таныклык һәм аларның рус теленә нотариаль расланган тәрҗемәсе (булган очракта) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 16. | 1А-5А, 1Б-5Б | Россия Федерациясенең гражданлык хәле актларын теркәү органнары яки консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык (булган очракта) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 17. | 1А,5А, 1Б,5Б | Оешма хезмәткәрен социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә алу өчен җирле үзидарә органы җитәкчесе адресына оешманың үтенече | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 18. | 1А-5А, 1Б-5Б | Махсус салым режимнарын кулланучы физик затларның, индивидуаль эшкуарларның агымдагы елга керемнәре турында белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 19. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Россия Федерациясе законнары нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу өчен җибәрелгән (җәлеп ителгән) федераль башкарма хакимият органнары (федераль дәүләт органнары) тарафыннан бирелгән гражданның махсус хәрби операциядә катнашуын раслаучы белешмә | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 20. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Махсус хәрби операциядә катнашкан һәм һәлак булган (вафат булган) кешенең үлеме турында таныклык күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 21. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Махсус хәрби операциядә катнашу яки аның үткәрелүе белән бәйле бурычларны турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә махсус хәрби операциядә катнашучының һәлак булуын (үлемен) раслый торган документлар күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 22. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Махсус хәрби операциядә катнашу яки аның үткәрелүе белән бәйле | Бердәм портал, Республика |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | бурычларны турыдан-туры үтәү белән бәйле рәвештә һәлак булган (вафат булган) кешенең үлеменә китергән җәрәхәт (яралану, имгәнү, контузия) яки авыруның сәбәпле бәйләнеше турында хәрби-медицина комиссиясе нәтиҗәсе күчермәсе | порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 23. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Татарстан Республикасы территориясеннән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылу фактын йә махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Татарстан Республикасындагы хәрби комиссариатларда йә Татарстан Республикасында урнашкан хәрби частьләрдә Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзүне раслый торган документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 24. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Махсус хәрби операциядә катнашуны тәмамлауны раслый торган документлар | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 25. | 4А, 5А, 4Б,5Б | Махсус хәрби операциядә катнашу тәмамланган көнгә йә махсус хәрби операциядә катнашучы һәлак булган көнгә Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 26. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүчегә, һәр гаилә әгъзасына һәм бергә теркәлгән барлык гражданнарга персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (10 нчы кушымта) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 27 | 1А-5А, 1Б-5Б | Финанс-шәхси счетның күчермәсе | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| *Хезмәтне күрсәтү өчен гариза бирүче үзе тапшырырга мөмкин булган документлар* | | | |
| 1. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүче гаилә әгъзаларының 14 яшькә җитмәгән балалары өчен туу турында таныклык. | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 2. | 1А-5А, 1Б-5Б | Мөрәҗәгать итүчегә һәм/яки аның гаилә әгъзаларына язылышу факты булганда язылышу турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | комитет, КФҮ |
| 3. | 1А-5А, 1Б-5Б | Аталыкны билгеләү турында таныклык (аталыкны билгеләү факты булганда) | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 4. | 1А-5А, 1Б-5Б | Аерылышу турында таныклык, әгәр аерылышу мизгеленнән 5 ел узмаган булса, күрсәтелгән чорда аерылышу факты булган очракта; | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 5. | 1А-5А, 1Б-5Б | Фамилиясе, исеме, атасының исеме үзгәрү факты булганда фамилияне, исемне, атасының исемен үзгәртү турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 6. | 1А-5А, 1Б-5Б | Үлем факты булган очракта, гаилә составын раслау өчен үлеме турында таныклык | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 7. | 1А-5А, 1Б-5Б | Торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 8. | 1А-5А, 1Б-5Б | Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66.1 статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган, тиешле рәвештә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә таныкланган хезмәт кенәгәсе (эш бирүче тарафыннан таныкланган барлык битләрнең күчермәсе) һәм (яисә) кәгазьдә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 9. | 1А-5А, 1Б-5Б | Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасы законнары нигезендә алынган Физик затлар файдасына иминият кертемнәрен түләүчеләр тарафыннан башкарылган түләүләр турында, пенсияләр, пособиеләр һәм түләүләр рәвешендә социаль ярдәмнең башка чаралары турында белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, Башкарма комитет, КФҮ |
| 10. | 1А-5А, 1Б-5Б | Пособиеләрне билгеләү турында белешмәләр | Бердәм портал, Республика порталы, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Башкарма комитет, КФҮ |
